| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**05.05.2025**

Зеленодольск шәһәре

**КАРАР**
**№ 1191**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районы хисапчы хезмәтләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын түләүне оештыру һәм шартлары турында» 2019 елның 23 апрелендәге 962 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Хисапчы хезмәтләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын камилләштерү максатыннан, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районы хисапчы хезмәтләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын түләүне оештыру һәм шартлары турында» 2019 елның 23 апрелендәге 962 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 1 нче кушымтасындагы «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының финанс-икътисад хезмәте» муниципаль казна учреждениесе хезмәткәрләренең хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында нигезләмәнең 3 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. "ЗМР БК финанс-икътисадый хезмәте" МКУ хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Хезмәткәр вазыйфалары | Вазыйфаи оклад, сум |
|---|---|
| Муниципаль учреждение җитәкчесе | 41 500 |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе урынбасары | 39 800 |
| Бүлек башлыгы | 33 500 |
| Бүлек башлыгы урынбасары | 29 700 |
| Әйдәп баручы хисапчы | 29 500 |
| Әйдәп баручы икътисадчы | 29 500 |
| Сатып алулар өлкәсендә әйдәп баручы белгеч | 29 500 |
| Әйдәп баручы ревизор | 29 500 |
| Хисапчы | 27 800 |
| План-техник бүлеге белгече | 27 800 |
| Ревизор | 27 800 |
| Сатып алулар өлкәсендә белгеч | 27 800»; |

1.2. Карарның 2 нче кушымтадагы Зеленодольск муниципаль районы муниципаль берәмлекләре Башкарма комитетлары хисапчы хезмәтләре хезмәткәрләренең (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән

вазыйфалардан тыш) хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында нигезләмәнең 3 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«3. Хисапчыларның вазыйфаи окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Муниципаль берәмлектәге халык саны | Вазыйфаның исеме, оклад (сум) | |
|---|---|---|
| | Баш хисапчы | Хисапчы |
| 3,5 меңгә кадәр кеше | 28 200 | |
| 3,5 меңнән артык кеше | 29 700 | |
| 1,9 меңнән артык кеше | | 27 000»; |

2. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 01 ноябрендәге «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районы хисапчы хезмәтләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында» 2019 елның 23 апрелендәге 962 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 4103 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2025 елның 1 маеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (htpp:/pravotatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче З.Ф. Хәбибуллин